**Башлангыч сыйныфларда эш программасына аннотация**

Башлангыч сыйныфлар өчен татар теленнән эш программасы:

1.Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программасы” Төзүче авторлары Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В.А.Гарипов (1-11 сыйныфлар, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011)

2. Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

Сәгатьләр саны: атнасына 3 сәгать исәбеннән елына 102 сәгать.

Укыту – методик комплекты:

“Рус телендә урта(тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен “Татар теле һәм әдәбияты” Үрнәк программалар. (Х.Х.Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова, Казан. Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел );

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә укучыларның телдән һәм язмача аралашу күнекмәләрен камилләштерү, татар теленнән системалы фәнни белем бирү белән беррәттән, татар дөньясы, татар әдәбияты турында күпкырлы мәгълүмат җиткерү, ягъни укучыларның комуникатив компетенцияләрен үстерү гомуми максат итеп билгеләнә.

Татар теле укытуның максаты:

1.Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну,омтылыш,эзләнүгә теләк уяту,үз милләтеңә,телеңә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.

2.Балаларда татар теле буенча мәгълүматлылык булдыру:

а)фонетика,лексика,сүз ясалышы,грамматика,стилистикага караган башлангыч мәгълүмат бирү;

б)телебезнең орфоэпиясе,лексикасы,грамматикасы,пунктуациясе буенча күнекмәләр булдыра башлау.

3.Укучыларда аралашу өлкәсенә караган мәгълүматлылык булдыру.Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча әйткәнне аңларга,аңлаганны тыңлаучыга җиткерергә,дөрес һәм матур итеп укырга,укыганның эчтәлеген сөйләргә,аерым темалар буенча әңгәмәләр кора белергә,аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.

4.Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.

5.Укучыларда татар этнокультурасы буенча мәгълүматлылыкны үстерү.

Бурычлары:

Гамәли максатка ирешү өчен,укучыларда татар сөйләмен тыңлап аңлау күнекмәләрен булдыру;

диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләрен үстерү;

төрле жанрдагы татар текстларын аңлап укуга өйрәтү;

дөрес язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен булдыру;

татар теленең фонетик, орфоэпик, лексик, грамматик нигезләрен һәм үзенчәлекле тел күренешләрен гамәли үзләштерү.

*Танып белү универсаль уку гамәлләре:*

- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- алфавитта тамгаларның(хәрефләрнең) урнашу тәртибен белү ;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;

*Регулятив универсаль уку гамәлләре:*

-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

*Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:*

- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;

- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)
*Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:*
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

**Башлангыч сыйныфларда эш программасына аннотация**

Башлангыч сыйныфлар өчен әдәби укудан эш программасы:
Ф.Г.Галимуллин, З.Н.Хәбибуллина, Х.Г.Фәрдиева тарафыннан төзелгән ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган "Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программасы", Казан: "Мәгариф", 2011 ел,
Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.
Рус мәктәбенең башлангыч сыйныфларында укучы татар балалары өчен төзелгән әдәби уку программасы түбәндәге максат һәм бурычларны үз эченә ала:
- татар әдәбияты, аның аеруча күренекле вәкилләре турында беренчел күзаллау булдыру;
- әдәби әсәрне тыңлап һәм укып аңлау күнекмәләре булдыру;
- текст белән танышу, эчтәлеген сөйләп бирү күнекмәләрен формалаштыру, аны камилләштерә бару;
- әдәби текстларны дөрес, тиз һәм тора – бара сәнгатьле итеп укуларына ирешү;
- мөстәкыйль рәвештә әдәби әсәрләрне укырга һәм үзләштерергә күнектерү, белемгә омтылыш, китапка карата кызыксыну тәрбияләү;
- татар әдәбияты белән бергә башка халыкларның сүз сәнгатенә дә кызыксыну тәрбияләү;
- укучыларның иҗади фикер йөртүен, затлы зәвыгын үстерү;
- әдәби әсәрләр ярдәмендә үз- -үзенең әдәпле тотуга ихтыяҗ тәрбияләү;
- дөрес, бәйләнешле итеп телдән һәм язма сөйләмгә өйрәтү.

*Танып белү универсаль уку гамәлләре:*
- дәреслектә ориентлаша белү;
- шартлы билгеләрнең телен белү;
- рәсем һәм схемалар нигезендә биремнәр үтәү;
- төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- алфавитта тамгаларның(хәрефләрнең) урнашу тәртибен белү ;
- материаль объектлар кулланып биремнәр үтәү;
- дәреслек һәм мөстәкыйль эш дәфтәрендәге мәгълүматлар белән эшли белү;
*Регулятив универсаль уку гамәлләре:*
-кагыйдәләрне, күрсәтмәләрне истә тотып гамәлләр кылу;
- гамәлләрне таләп ителгән вакытта башлау һәм тәмамлау;
- үз эшчәнлегеңне контрольгә алу, биремне үтәүнең дөреслеген тикшерү;
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- эшләнгән эшнең сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.
*Шәхескә кагылышлы универсаль уку гамәлләре:*
- дәреслек геройларына, күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз уңышларын/уңышсызлыкларың турында фикер йөртү;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү;
- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- мәгънә барлыкка китерү («Минем өчен моның нинди мәгънәсе һәм әһәмияте бар?» - дигән сорау кую)
*Коммуникатив универсаль уку гамәлләре:*
- тормыш тәҗрибәсен куллану;
- күршең белән хезмәттәшлек итү.

**5 нче сыйныфның татар теленнән эш программасына аннотация**

5 нче сыйныф өчен "Татар теле " курсының эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде: Федераль дәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән “Рус телендә Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы (татар балалары өчен)”, (төзүче-авторлары: Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова. В.А. Гарипова – Казан, 2011.), Рус мәктәбендә укучы татар балаларына татар теленнән үрнәк гомуми программа. V - IX сыйныфлар, (төзүче-авторлары: Ф.Ф. Харисов, Ч.М. Харисова. Г.Р. Шакирова - Казан, 2013.) Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планы.

Рус телендә белем бирү мәктәбендә татар балаларына татар теле укытуның максаты:

Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, аның аркылы башка телләрне дә өйрәнү теләге уяту; үз милләтеңә, аның мәдәни үзенчәлекләренә, гореф-гадәтләренә, ана телеңә мәхәббәт тәрбияләү; шулар аркылы башка милләтләргә, аларның гореф-гадәтләренә, мәдәниятләренә ихтирам уяту.

Балаларда туган телгә, аның яңгырашына, сүзлек байлыгына карата кызыксыну уяту. Тел күренешләрен аңларга, эзлекле фикер йөртергә өйрәтү. Фәнни-тикшерү эшчәнлеге алып баруга мотивация тудыру, проект эшләрен башкаруны дөрес оештыру. Тел берәмлекләрен урынлы кулланып, бәйләнешле сөйләм тудыру өстендә эшләү, аралашу компетенциясе булдыру.

Бурычлары:

- укучыларда, туган телгә сакчыл караш тәрбияләү;
- укучыларның сөйләм эшчәнлеген һәм фикерләү сәләтен, төрле шартларда әдәби телдә дөрес аралаша белү күнекмәләрен үстерү;
- татар теленең фонетик төзелеше, орфоэпик, орфографик нормалары турында белем бирү;
- телнең лексик байлыгын анализлый, күрә, таба белү сәләтен, осталыгын булдыру, үстерү, сүз байлыгын арттыру;
- татар теленең сүз ясалыш мөмкинлекләрен үзләштерү, гамәли кулланылышка кертү;
- алынган белемне һәм осталыкны тормышта максатчан кулланырга өйрәтү;
- сүзлекләр, дәреслек, өстәмә һәм белешмә әдәбият белән эш итү, уку, язу күнекмәләрен камилләштерү;
- үз милләтеңә, телеңә хөрмәт белән карау, шулай ук татар теле аша башка милләт вәкилләренә, аларның рухи мирасына мәхәббәт хисе тәрбияләү.

Уку фәненең уку планында тоткан урыны

Укыту-тәрбия эше рус телендә алып барыла торган мәктәпләрдә татар балаларына татар телен өйрәтү үз телләрен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш уяту, мәхәббәт хисләре тәрбияләүдә әһәмиятле роль уйный.

Укыту планында каралганча, татар теле дәресләре өчен эш программасы атнага 3 сәгать исәбеннән елга 105 сәгатькә төзелде.

Укытуның көтелгән нәтиҗәләре. Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр:

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү:
- милли горурлык, гражданлык хисләре формалаштыру;
- әхлак нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен үзләштерү;
- күршеңә ярдәм итүдә танып-белү инициативасы күрсәтү;
- үз алдыңа максат кую, аңа ирешү юлларын эзләү;
- уңышларыңа яки уңышсызлыкларыңа, аларның сәбәпләренә дөрес бәя бирү;
- - индивидуаль эшчәнлек стилен формалаштыру:
- төрле мәгълүмат чараларын (сүзлекләр, Интернет ресурслар һ.б.) танып-белү һәм

аралашу вакытында куллану;
- актив, мөстәкыйль, иҗади фикер йөртүче, фәнни-тикшеренү эшчәнлеген башкара алырлык шәхес буларак формалашуны дәвам итү;
- үзең алган белем күнекмәләрен тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү.

Метапредмет нәтиҗәләр Танып-белү гамәлләре:

- танып-белү юнәлешендәге максатларны билгеләү;
- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра
- белүе, бәяләве, үзенең кызыксынучанлык өлкәсен билгеләве;

мөстәкыйль рәвештә теманы, куелган проблеманы ача белү, фикер йөртү;

- уку мәсьәләсе тирәсендә логик фикерләү;
- фикерләүдә логик чылбыр төзү;
- тема тирәсендәге төп билгеләрне аерып алу нигезендә кагыйдә формалаштыру;
- төрле мәгълүмат чаралары белән эшли, кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә куллана белү;
- фонетик анализ ясау күнекмәләре булдыру;
- сүз ясалыш ысулларыннан файдаланып сүзләр ясый белү , сөйләм эшчәнлегендә алардан дөрес һәм урынлы файдалана белү;
- телне әдәбият, рәсем һәм музыка сәнгате белән бәйләп, сүз сәнгатенең кыйммәтен күрсәтү, матурлыкны танырга өйрәтү;
- тел берәмлекләренең әдәби әсәр тудырудагы ролен билгеләү;
- татарчадан русчага, русчадан татарчага тәрҗемә итү юлы аша фразеологик берәмлекләрнең эчтәлегендәге фәлсәфәне үзләштерү.

Коммуникатив УУГ

- тыңлый белү;
- диалог төзүдә һәм коллектив фикер алышуда катнашу;
- сыйныфташлары һәм укытучы белән уку эшчәнлеген оештыруда хезмәттәшлек итү;
- төрле фикерләрне исәпкә алып эш итү;
- үз фикерен дәлилли белү, тормыштан мисаллар китерү;
- төрле җавапларны тыңлау, чагыштыру, нәтиҗә ясау;
- үз фикерен тулы һәм төгәл итеп әйтә белү;
- күмәк эш вакытында уртак фикергә килү;
- мәгълүмат туплауда үзара хезмәттәшлек итүдә инициативасы күрсәтү;
- укылган текстлар буенча сораулар бирә алу;
- бирелгән текстларның дәвамын үзлектән сөйләп карау,фикер әйтү автор фикере белән чагыштыру;
- үз эшен контрольдә тоту, сыйныфташларына ярдәм итү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы ролен билгеләү;
- үз фикерләрен телдән һәм язмача җиткерә белү;
- башкаларны тыңлый, киңәш бирә белү;
- сыйныфташлары каршында төрле темаларга, башкарылган проектлар буенча чыгыш ясау;
- иптәшенең гамәлләрен бәяләү, күрше белән хезмәттәшлек итү.

Регулятив УУГ:

- дәреснең проблемасын (тема) һәм максатларын мөстәкыйль формалаштыру;
- проблеманы аңлап гипотеза чыгару, үз фикереңне дәлилләр китереп раслый белү, телдән (диалогик, монологик) һәм язма сөйләмдә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешен аерып алу, нәтиҗәләрне формалаштыру;
- максатка ирешү юлларын билгеләү;
- үз эшчәнлегеңнең нәтиҗәле булуына ирешү, үз эшчәнлегеңне контрольгә алу;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларын бәяләү;

- кагыйдә, күрсәтмәләрне истә тоту һәм аларга ияреп гамәлләр кылу;
- эшләнгән эшкә бәя бирү, сыйфатын һәм дәрәҗәсен билгеләү.

Предмет нәтиҗәләр:

- фонетик, сүз төзелеше һәм лексик берәмлекләр белән эш итүне ныгыту;
- исем, орфоэпик һәм орфографик кагыйдәрне үзләштерү, гамәли куллана белү;
- сүзнең лексик мәгънәсен билгели һәм сөйләмдә урынлы куллана белү;
- тел материалы белән логик фикерләүне сорый торган эш төрләрен башкару;
- телнең сүзлек составын куллану өлкәсе, активлыгыннан чыгып урынлы файдалану;
- сүзләрнең төзелешен һәм ясалышын тикшерү;
- бирелгән темаларга, тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп, кечкенә хикәяләр язу;
- укучыларны иҗади эшчәнлеккә тарту, проект эшләре белән кызыксындыру.

**5 нче сыйныфның татар әдәбиятыннан эш программасына аннотация**

“Татарәдәбияты”курсының эш программасы Федеральдәүләт белем бирү стандартларының таләпләренә туры китереп, “Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V-Ixсыйныфлар )өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа” (Ф.Х.Җәүһәрова, К.С.Фәтхуллова. Казан, 2013) һәм “Рус телендәгомуми төп һәм урта белем бирү оешмаларының татар сыйныфлары өчен татар әдәбиятыннан программа” (Төзүче-авторлар: Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина), 5 нче сыйныф өчен Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллиналар эшләгән (Казан, Мәгариф – Вакыт, 2014), Татарстанның Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән дәреслеккә, Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

Дәреслек: Татар әдәбияты: рус телендә төп гомуми белем бирү оешмалары өчен д-лек (татар телен туган тел булара көйрәнүче укучылар өчен). 5нче с-ф.Ике кисәктә./ Ф.Ф.Хәсәнова, Г.М.Сафиуллина, М.Я.Гарифуллина. – Казан: «Мәгариф – Вакыт»нәшр., 2014. – 143 б.: рәс.б-н.

Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларынаәдәбият укытуның төп максаты һәмбурычлары

1. Укучының татар әдәби телен үзләштерүенә, текстны аңлап, сәнгатьлеитеп, йөгерек укуына, дөрес яза белүенә, әдәби тел нормаларын саклап, төрле темаларгаиркен сөйләшүенәирешү,матурәдәбиятәсәрләренмөстәкыйльукукүнекмәләреформалаштыру, телдән һәм язма сөйләмнәренүстерү.
2. Балаларнытатарәдәбияты,халыкавызиҗаты,татархалкыныңҗыр-музыкасы, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларныңәсәрләрен үзләштерүләренә ирешү, матур әдәбият әсәрләрен (яки әдәби әсәрләрдән өзекне)укып үзләштерү, алар турында үз фикерләрен әйтергәөйрәтү.
3. Әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлату һәм кулланыргаөйрәтү.
4. Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы,милләттәшләребез тормышы турында мәгълүматбирү.
5. ХалыктарихынһәммирасынөйрәнүашаукучылардаВатанга,халыкка,туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм гомумән кешегә ихтирам,мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү. Эстетик тәрбия бирү, табигатькә сакчыл, мәрхәмәтле карашуяту.
6. Татар,русһәмбашкахалыкларәдәбиятларынчагыштырыпкараукүнекмәләре булдыру.
7. Әдәби әсәрләрне өйрәнү барышында укучыларны сәнгатьле укуалымнарына өйрәтү дә әһәмиятле. Бу җәһәттән эш түбәндәге юнәлешләрдә алыпбарыла:

- татар теленең үзенчәлекле авазларын әйтү күнекмәләребулдыру;
- сүз басымын дөрес куя белү;
- логик басымны дөрес куя белү;
- җөмләне фразаларга бүлү һәм дөрес пауза беләнуку;
- тавышны дөрес төшерә һәм күтәрә белү, ягъни интонацияне дөрескуллану күнекмәләре булдыруһ.б.

Уку фәненең уку планында тоткан урыны

Мәктәптә әдәбият предметы – кирәкле, әһәмиятле предметларның берсе.Ул укучыларны тормышны үзенчәлекле итеп танып белергә өйрәтә, хисси-эмоциональдөньясын баета, эстетик зәвык тәрбияли, сөйләмен үстерә, гомумән, шәхес итеп тәрбияләүдә зурроль уйный.

Татар әдәбияты төп мәктәптә 5-9 сыйныфларда өйрәнелә. Укыту планында каралганча,татар әдәбияты дәресләре өчен 5 нчесыйныфта 2сәгать исәбеннән елга70(35) сәгать күздә тотыла.

Укытуның көтелгән нәтиҗәләре

- сүз сәнгатенең образлы табигатен тою;
- өйрәнгән әдәби әсәрнең эчтәлегенаңлау;
- классик әдипләрнең (К.Насыйри, Г.Тукай, Г.Ибраһимов, М.Җәлил)биографик белешмәләре белән танышу;
- өйрәнгән әдәби-теоретик төшенчәләрне истәкалдыру;
- әдәби текстны кабул итү һәм анализлау;
- әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару,укыган буенча тезислар һәм план төзү;
- әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау;
- укыган әсәрнең темасын, проблемасын билгеләү;
- геройларга характеристика бирү;
- сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу;
- әдәби әсәрдәге эпизодларны һәм геройларны чагыштыру;
- укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү;
- әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку;
- кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану;
- өйрәнелгән әсәрләргә бәйле рәвештә телдән һәм язмача фикербелдерү;
- укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерне дәлиллибелү;
- татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәмязмача бәйләнешле тексттөзү;
- эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү;
- аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, интернет чаралары һ.б. ашаэзләү.

Шәхескә кагылышлынәтиҗәләр

- шәхеснең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү, күпмилләтле илебезгә карата ярату хисләре, татар әдәбиятына һәм башка халыклар әдәбиятына, мәдәниятына ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру;
- активлыкка, мөстәкыйль фикер йөртүгә, акыл һәм рухи эшчәнлеккә өйрәнү,шәхес буларак формалашуны дәвамитү;
- үзең белән идарә итүгә юнәлдерелгән белем һәм күнекмәләрне тормышның төрле шартларында куллана белергә өйрәнү, тормышта үз урыныңны күзаллый башлау;

Метапредмет нәтиҗәләр

“Әдәбият” курсын өйрәнүнеңметапредме тнәтиҗәләре булып, универсаль уку-укыту гамәлләре формалаштыру санала (УУГ.)

Танып белүУУГ(ТБУУГ):

- укучының үз эшчәнлеген мөстәкыйль рәвештә оештыра белүе,бәяләү;
- мөстәкыйль рәвештә төрле текстларны укый белү, өстәмә материалларны табаһәм тиешле урында куллана белү;
- кирәкле мәгълүматны таба, анализлый һәм үз эшчәнлегендә кулланабелү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты, башка халыклар әдәбиятлары белән бәйләп укып, әдәбиятлар арасындагы уртак проблемаларны, уртак кыйммәтләрне күрсәтү аша, дөнья культурасы белән танышу;

- бәхәсләшү, үз фикерен дәлилләү, анализ ясау,йомгаклау.

Коммуникатив УУГ(КУУГ):

- төрле фикерләрне исәпкә алып эшитү;
- күмәк эш вакытында бер фикергә киләбелү;
- коммуникатив күнекмәләрнең кеше тормышындагы роленбилгеләү;
- үз фикереңне телдән һәм язма формада җиткерәбелү;
- текст буенча сораулар куябелү
- бәхәсләшү, үз фикерләрендәлилләү.

Регулятив УУГ(РУУГ):

- мөстәкыйль рәвештә дәреснең проблемасын һәм максатларынформалаштыру;
- проблеманы аңлый белү, гипотеза чыгару, материалны төзү, үз фикереңнераслау өчен дәлилләр сайлый белү, нәтиҗәләрнеформалаштыру;
- уку проблемасын чишү өчен плантөзү;
- укытучы белән бергәләп, үз эшен, иптәшләренең җавапларынбәяләү.

Предметнәтиҗәләре

- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗадиуку;
- әдәбиәсәрләрнеанализлау,аларныңбилгелебержанргакаравын,теманыаңлау һәм формалаштыру, идеясен тотып алабелү;
- геройларга характеристика бирү, төрле әсәрдәге бер яки берничә геройбелән чагыштырабелү;
- татар әдәбияты һәм мәдәниятенең әхлакый һәм рухи кыйммәтләренүзара якынайту, башка халыкларныкы беләнчагыштыру;
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне ишетеп кабул итү, аңлаешлы уку, эчтәлекне дөресаңлау;

әдәбиятның образлы дөньясын сүз сәнгате күренеше буларак аңлау.

**Татар төркемнәренә татар теленнән эш программасына аннотация**

**6 нчы сыйныф.**

Төп гомуми белем бирү мәктәбе өчен үрнәк программа “ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган «Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен һәм әдәбиятын укыту программалары (татар балалары өчен), 1-11 нче сыйныфлар» (Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2011 ел),

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында бирелгән “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына татар теле: үрнәк гомуми программасына (V – 1X сыйныфлар)” (Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, Г.Р.Шакирова. К а з а н . 2013 ел), Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

6 нчы сыйныфта татар теле дәреслеге. (Максимов Н.В., Хамидуллина М.З. 2011)

Эш программасы структурасы

Эш программасы түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуы, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән тора.

Татар теленнән 6 нчы сыйныфта белем бирүнең максатлары һәм бурычлары:

- сүз төркемнәре турында тирән мәгълүмат бирү һәм аларны аерырга өйрәтү
- укучыларның сүз байлыгын сүз төркемнәре хисабына баету;
-морфология курсын бәйләнешле сөйләмә һәм язма телгә таянып ныгыту;
- сүз төркемнәрен үзләштереп, дөрес укырга һәм язарга өйрәтү
-укучыларның башлангыч мәктәптә татар теленең грамматик нигезләреннән алган белемнәрен системалаштыру, катлаулырак формаларда өйрәтүне дәвам итү;
-укучыларның иҗади һәм мөстәкыйль фикерли алу мөмкинлекләрен үстерү, үз фикерләрен дәлилләргә күнектерү;

-телнең төп грамматик чараларын сөйләм процессында куллануга ирешү;
-татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллауга, аларны тиешенчә куллана белүгә өйрәтү;
-телнең милли мәдәниятнең чагылышы булуын, тел һәм тарих бердәмлеген аңлату; татар теленең милли – мәдәни үзенчәлегенә төшендерү; татар һәм башка халыкларның рухи мирасына ихтирам тәрбияләү

Сөйләм эшчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм язу) үзләштерү.

Аралашу процессында татар әдәби теле нормаларын дөрес куллана белү.

Текст эчтәлеген кыскача, тулы, сайлап алып сөйләү. Диктант, изложение, сочинение язу. Төрле стиль һәм жанрдагы текстлар төзү: хат, мәкалә,

Предметның укыту планында тоткан урыны:мәктәпнең –2015-2016 нчы уку елына уку-укыту планы нигезендә "Татар телен"н атнага (35 атна) 3 шәр сәгать исәбеннән, елга 105 сәгать укыту каралган.

**7нче сыйныф**

Төп гомуми һәм урта белем мәктәбе өчен үрнәк программа. "Рус телендә төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (I-XI сыйныфлар) өчен татар теленнән үрнәк программа", төзүче-авторлары: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.
«Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче с-флар", төзүче-авторы: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011,
Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде. 7 нче сыйныфта татар теле дәреслеге. (Р.Ә.Асылгәрәева, М.З.Зиннәтова, Казан "Мәгариф" нәшрияты, 2010)
Эш программасы структурасы
Эш программасы түбәндәге өлешләрдән тора: аңлатма язуы, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән тора.
Эш программасының белем бирү максатлары:
Ана теленнән лингвистик компетенциягә (мәгълүматлы булу) ия булу.
Аралашу компетенциясенә ия булу, ягъни башкалар әйткәнне аңлау һәм үз фикереңне белдерү өчен тупланган белем, осталык, күнекмәләр җыелмасына, татар әдәби теле нормаларына ия булу.
Этнокультура компетенциясенә ия булу – телне мәдәни яссылыкта, ягъни рухи, эстетик тәрбия һәм белем бирү чарасы буларак өйрәнү; тормыш-көнкүреш, гореф-гадәт үзенчәлекләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен белү.
Төп бурычлар:
1.Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле белем бирү.
2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру.
3. Телдән һүм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү.
4. Дәреслек, өстәмә материал, белешмә әдәбият белән эш итү күнекмәләрен ныгыту.
Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр:
1. Сүз төркемнәреннән фигыльне үзләштерү, морфологик анализ ясый белү.
2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.
3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау.
4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.
5. Аваз ияртемнәрен, хәбәрлек сүзләрне, бәйләгеч сүз төркемнәрен, модаль сүз төркемнәрен тикшерү үрнәкләрен камил белү.
6. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.
7. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу.
Укыту фәненең эш программасында тоткан урыны
Укыту планында каралганча, татар теле дәресләре өчен эш программасы 105 сәгатькә бүленеп, атнага 3 сәгать исәбеннән төзелде.

**8нче сыйныф.**

Федераль дәүләт белем стандартлары компонентына нигезләнгән төп гомуми белем мәктәбе өчен үрнәк программа.. “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар телен укыту программасы”на(татар балалары өчен) үрнәк программага (төзүче-авторлары: Ф. Ф. Харисов, Ч. М. Харисова, Г.Р. Шакирова, Казан: 2013),

Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: “Татар теле һәм әдәбияты”, 1-11 нче сыйныфлар. Ф.Ф. Харисов, Ч.М.Харисов, В.А. Гарипова. Казан Татарстан Китап Нәшрияты 2011 Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

8нче сыйныф татар төркемендә татар теленә өйрәтүнең максатлары һәм бурычлары:

укучыларны үз иленең гражданнары һәм патриотлары итеп тәрбияләүдә, аларны халыкның рухи, әхлакый һәм мәдәни кыйммәтләрен үзләштерердәй итеп үстерүдә татар теленең әһәмиятен җиткерү;

укучыларның рухи-әхлакый сыйфатларын булдыру, аларның төрле яклап - гражданлык, иҗтимагый, шәхси үсешен тәэмин итү, яшь буынның иҗади сәләтен үстерү, сәламәтлеген саклау һәм ныгыту юнәлешендә эшләү;

8нче сыйныфта туган тел буенча төп мәктәптә белем бирүдә эзлеклелекне тәэмин итү;

балаларга төп белемне сыйфатлы итеп бирү, аларны җәмгыятьтә үз урынын табардай, төрле милләт вәкилләре арасында үзара дус һәм тату яшәрдәй шәхес итеп тәрбияләү;

белем һәм тәрбия биргәндә, укучыны кабатланмас аерым бер үзенчәлеккә ия булган шәхес итеп күзаллау;

гади җөмлә синтаксисын үзләштергәндә белем һәм күнекмәләрне укучыларның үз сөйләмнәрендә дөрес һәм тиешенчә куллана белүләренә ирешү, орфоэпик, орфографик һәм пунктуацион яктан грамоталы шәхес итеп тәрбияләү;

балаларда киләчәктә алачак һөнәрләренә аңлы караш тәрбияләү, аларның җәмгыятьтә үз урыннарын таба белүләренә ирешүдә туган телнең әһәмиятен аңлату;

укучыларны шәхси, иҗтимагый, гаилә һәм дәүләт таләпләренә туры килердәй белем һәм күнекмәләр белән коралландыруны күз уңында тоту;

укучылар ала торган белем һәм тәрбиягә бердәй таләпләр белән якын килү, шәхесне киләчәк иҗимагый тормышта үз урынын табардай итеп тәрбияләү;

уку-укыту эшендә дәрестән тыш формаларны да тиешенчә файдалану;

сыйныфтан тыш эшләр аша укучыларның сәләтен ачыклау, аларга һөнәри юнәлеш алуда ярдәм итү, укуда һәм җәмәгать эшләрендә катнашу аша сәләтле балаларны барлау һәм аларны алга таба үстерү,

Предметның укыту планында тоткан урыны: 8нче сыйныфта рус телендә төп гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программа буенча да, мәктәпнең 2015-2016 нчы уку елына уку-укыту планы нигезендә дә “Татар теле”н атнага (35 атна) 3 әр сәгать исәбеннән, елга 105 сәгать укыту каралган.

**9 нчы сыйныф.**

Программа “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11 нче с-флар (басма өчен Ч.М.Харисова, К.С.Фәтхуллова, З.Н.Хәбибуллина җаваплы). – Казан:Татар.кит.нәшр., 2011. – 239 б. Җыентыгындагы Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, В.А.Гариповалар төзегән “Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар теленукыту программасы (татар балалары өчен)”на, Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

*Эш программасы структурасы.*

Татар теленнән эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

*Эш программасының эчтәлеге.*

Татар теле укытуның максатлары:

Укучыларда татар теленә хөрмәт һәм аны ярату, рухи кыйммәт һәм кешелек дөньясының аралашу, белем алу чарасы буларак аңлы караш тәрбияләү;
Укучыларның сөйләү һәм фикерләү сәләтен үстерү, аларны татар әдәби телен тормышның төрле өлкәләрендә иркен куллана алырлык шәхесләр итеп тәрбияләү; дөрес сөйләм эшчәнлегенең үзара аралашу чарасы икәнен билгеләү;
Татар теле, аның төзелеше, кулланылышы турында мәгълүмат алу; татар әдәби теленең төп нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллау, аларны тиешенчә куллана белү; сүз байлыгын арттыру, сөйләмдә кулланыла торган грамматик чараларны төрлеләндерү;
Телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне сөйләмдә дөрес куллана белү.

Укыту планында 9 нчы сыйныфта татар теленнән атнага 2 сәгать вакыт бирелә. Татар теленнән тематик планны “Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары”на (Ф.Ф.Харисов, Ч.М. Харисова,В.А. Гарипова, Р.Р. Җамалетдинов, Р.Ф.Җамалетдинова. Казан. “Мәгариф” нәшрияты, 2003) нигезләнеп төзедек. Программада 70 сәгать каралган: теоретик материал –37 сәгать, кабатлау -18 сәгать, бәйләнешле сөйләм үстерү – 15сәгать, төрле типтагы тикшерү эшләре - 19 сәгать.

**10нчы сыйныф.**

Төп гомуми һәм уртабелем мәктәбе өчен үрнәк программа. “Рус телендә төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (I-XI сыйныфлар) өчен татар теленнән үрнәк программа”, төзүче-авторлары: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.
«Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче с-флар”, төзүче-авторы: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011, (37б), Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.
10нчы сыйныф татар төркемнәрендә татар теленә өйрәтүнең максат һәм бурычлары:
- укучыларда гражданлык һәм патриотик хисләр тәрбияләү;
- татар халкына хас булган рухи, әхлакый һәм мәдәни төшенчәләр турында мәгълүмат бирүне дәвам итү;
- татар теленең эчке үзенчәлекләренә төшендерү;
- ана телендә аралаша белергә өйрәтү һәм аны үстерү;
- татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, шушы тел нормаларын саклап, татар телендә тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә аралаша-аңлаша белү күнекмәләрен камилләштерү;
- тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллану күнекмәләрен камилләштерү;
- текст белән эшләү, аннан кирәкле мәгълүматны сайлап ала белү һәм аны тиешенчә үзгәртә алу күнекмәләрен үстерү;
- ана теленнән алган белем һәм күнекмәләрне укучыларның үз сөйләмендә куллана алуларына ирешү;
- дәресләрдә алган белемнәрне аралашуның төрле өлкәләрендә урынлы һәм дөрес итеп куллана белү;
- укучыларның орфографик һәм пунктуацион грамоталылыгын үстерү;
- укучыларда җәмгыяви яктан җайлашу һәм сөйләм барышында аралашучыга уңай йогынты ясау осталыгын үстерү.

Предметның укыту планында тоткан урыны: рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программа буенча 10 нчы сыйныфта татар теле дәресләре 70 сәг каралган, мәктәпнең 2015-2016 нчы уку елына уку-укыту планы нигезендә “Татар теле”н атнага (35 атна) 1 әр сәгать исәбеннән, елга 35 сәгать укыту каралган.

**11нче сыйныф.**

Төп гомуми һәм урта белем мәктәбе өчен үрнәк программа. “Рус телендә төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (I-XI сыйныфлар) өчен татар теленнән үрнәк программа”, төзүче-авторлары: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.

«Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче с-флар", төзүче-авторы: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011, (39 б), Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.
Рус мәктәбенең 11 нче сыйныфы татар төркемнәрендә татар теле укытуның төп максатлары:
1.Укучыларда лингвистик, коммуникатив(аралашу), этнокультура өлкәсенә караган (культурологик) компетенцияләр булдыру.
2. Ана телендә камил сөйләшү, фикереңне җиткерә белү, тел һәм сөйләм күнекмәләрен тирән үзләштерү.

Төп бурычлар:

1.Татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле белем бирү.
2. Сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру.
3. Телдән һүм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү.
4. Дәреслек, өстәмә материал, белешмә әдәбият белән эш итү күнекмәләрен ныгыту.

Укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр:

1. Орфография, орфоэпия нормаларын үзләштерү, фонетик анализ ясый белү.
2. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.
3. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау
4. Сүзләргә фонетик, морфологик, синтаксик анализ ясый белү күнекмәләрен булдыру, анализ үрнәкләрен камил белү.
5. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.
6. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.
7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.
8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.
9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу.

Предметның укыту планында тоткан урыны: рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программа буенча 11нче сыйныфта татар теле дәресләре 70 сәг каралган, мәктәпнең 2015-2016нчы уку елына уку-укыту планы нигезендә "Татар теле"н атнага (35 атна) 1 әр сәгать исәбеннән, елга 35 сәгать укыту каралган. Шулар арасында: диктант – 3 сәгать; инша язу – 1 сәгать; изложение - 2 сәгать. Программада 70 сәгать каралган, шул сәбәпле грамматика бүлеген 1сәг., морфология бүлеген 13сәг., синтаксис бүлеген 9 сәг., стилистика һәм сөйләм культурасы бүлеген 1 сәг., бәйләнешле сөйләм үстерүне 9 сәг., кабатлауны 2 сәгатькә кыскарттык.

**Татар төркемнәренә татар әдәбиятыннан эш программасына аннотация**

**6 нчы сыйныф.**

"Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә татар әдәбиятын укыту программасы"на (татар балалары өчен, 1-11 нче сыйныфлар .- Казан: Татар.кит.нәшр., 2011 ,76-77 нче битләр), Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.
Дәреслек. Татар әдәбияты: Рус телендә төп гомуми белем бирү мәкт.6 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия (татар балалары өчен).Авторлары: Ф.Г.Галимуллин, Ф.К.Мифтиева, И.Г.Гыйләҗев.- Казан: Мәгариф, 2010.
"Татар әдәбияты укытуның төп максаты һәм бурычлары
- матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү;
- төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби теоретик төшенчәләрне белү;
- балаларны татар әдәбияты, халык авыз иҗаты, татар халкының җыр-музыкасы, театры, сынлы сәнгате белән таныштыру, күренекле язучылар һәм аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү;
- укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү;
- әдәби әсәрне уку һәм анализлау;
- халык тарихын, мирасын өйрәнү аша Ватанга, халыкка, туган телгә мәхәббәт, олыларга, кечеләргә һәм, гомумән, кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек тәрбияләү.

Предметның укыту планында тоткан урыны:мәктәпнең 2015-2016 нчы уку елына уку-укыту планы нигезендә“Татар әдәбияты”н атнага (35 атна)2 шәр сәгать исәбеннән, елга 70 сәгать укыту каралган.

.

**7 нче сыйныф.**

Төп гомуми һәм урта белем мәктәбе өчен үрнәк программа. “Рус телендә төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (I-XI сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа”, төзүче-авторлары: Ф.Х. Җәүһәрова., Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.

Гамәлдәге авторлык программасы. «Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче с-флар”, төзүче-авторы: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011, Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.

Эш программасы структурасы.

Татар әдәбиятыннан эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

Эш программасының эчтәлеге.

Яңа стандарттагы иң мөһим таләп мондый: мәктәпне тәмамлаганда, «укучы үз алдына максат куярга һәм аны тормышка ашыру юлларын үзе таба алу дәрәҗәсенә күтәрелергә тиеш”. Бу – яңа стандартта эшлекле белем дип атала. Эшлекле белем – стандарт керткән яңалыкның әһәмиятле эчтәлеген ачып бирүче иң гомуми төшенчә. Белем алу гамәлләренең структурасын һәм принцибын стандарт үзе аңлата:

Структурасы – теория ярдәме белән, әдәби әсәрләргә анализ ясап, эчтәлек табу. Белем компонентлары өчәү: теория, өйрәнелә торган объект һәм алар арасындагы бәйләнеш – анализ гамәле.

Татар әдәбиятын укытуның максатлары:

матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белү;

дөньяга гуманлы караш, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, әдәбиятка һәм халыкның мәдәни кыйммәтләренә ярату һәм хөрмәт булдыру, ягъни рухи дөньясы бай булган шәхес тәрбияләү;

әдәби текстны эмоциональ кабул итүне, образлы һәм аналитик фикерләүне, иҗади күзаллауны, китап укучы культурасын һәм автор позициясен аңлауны, сәнгать төрләре белән берлектә әдәбиятның сүз сәнгате буларак үзенчәлеге турында карашны; матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗын; укучыларның телдән һәм язма сөйләмен үстерү;

әдәбият белеменең нигез төшенчәләренә һәм әдәбият тарихының төп факторларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау; әсәрләрдәге конкрет-тарихи һәм гомумкешелек эчтәлекне аерып ала белү; телдән һәм язма чыгышларда әдәби тел байлыгыннан дөрес файдалана белү күнекмәләре булдыру.

Укыту планында 7 нче сыйныфта татар әдәбиятыннан атнага 2 сәгать вакыт бирелә.

Арадаш аттестация эше: тест

Укыту дәрәҗәсе: база

Эш программасы үтәлү вакыты: 2015-2016 нчы уку елы

Мәктәпнең эш режимы: бер сменада 6 көнлек уку атнасы.

**8нче сыйныф**

Төп гомуми белем мәктәбе өчен үрнәк программа. “Рус телендә гомуми төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (V-IX сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа” Төзүче-авторлары: Ф. Х. Җәүһәрова Казан: 2013

«Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче с-флар”, төзүче-авторы: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011, Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми

белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.
8нче татар төркемендә татар әдәбиятына өйрәтүнең максаты һәм бурычлары:
татар әдәбияты текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү; төп әдәби-тарихи мәгълүматлардан, әдәби барышны тәэмин итүче төп әдипләр иҗаты турында хәбәрдар булу һәм гомум әдәби-теоретик төшенчәләрне татар әдәбиятына мөнәсәбәтле куллана белү;
татар әдәбияты тарихының төп фактларына нигезләнеп, әдәби әсәрне уку һәм анализлау күнекмәләре формалаштыру; әсәрләрдәге конкрет-тарихи һәм гомумкешелек өчен мөһим эчтәлекне күрә белү; телдән һәм язма чыгышларда әдәби тел байлыгыннан дөрес файдалану күнекмәләре булдыру;
әдәби текстны эмоциональ кабул итүне, образлы һәм аналитик фикерләүне, иҗади күзаллауны; китап укучы культурасын һәм автор позициясен аңлауны; сәнгать төрләре белән берлектә әдәбиятның сүз сәнгате буларак үзенчәлеге турында карашны; матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру; укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү;
татар әдәбияты, мәдәнияте белән кызыксыну, дөньяга гуманлы караш, татар халкының мәдәни кыйммәтләренә хөрмәт булдыру, ягъни рухи дөньясы бай һәм башка мәдәниятләрне хөрмәт белән кабул итүче шәхес тәрбияләү.
Предметның укыту планында тоткан урыны: мәктәпнең 2015-2016 нчы уку елына уку-укыту планы нигезендә “Татар теле”н атнага (35 атна) шәр сәгать исәбеннән, елга 70 сәгать укыту каралган. Рус мәктәбендә укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә торган әсәрләр минимумы шул 70 дәрестән торган курска өстәлгән.

**9 нчы сыйныф.**
Төп гомуми һәм урта белем мәктәбе өчен үрнәк программа. “Рус телендә төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (I-XI сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа”, төзүче-авторлары: Ф.Х. Җәүһәрова., Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.
Гамәлдәге авторлык программасы. «Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче с-флар”, төзүче-авторы: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011, Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе” гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.
Эш программасы структурасы.
Татар әдәбиятыннан эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.
Укучыларүзләштерегә тешле күнекмәләр:
-төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм сәнгатьле уку,аларга карата мөстәкыйль мөнәсәбәтеңне булдырү;
-әдәби әсәрне сюжет-композиция,тел-стиль ягыннан анализлау;
-шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрләрдән өзекләрне яттан сөйләү;
-сайлап алып яки тәкъдим ителгән язучының тормыш юлын,иҗатын үз карашыңа нигезләнеп сөйләү;
-фольклор әсәрләренең төрен,жанрын билгеләү һәм аларда үткәрелгән төп фикерне исбатлау;
-әсәр буенча план төзү һәм алар турында бәяләмә сочинение яки изложение язу;
-әдәби әсәрләр буенча иҗади инша язу;
- татр,тугандаш халыклар һәм рус әдәбиятындагы тематик яктан якын әсәрләрне чагыштырып өйрәнү,милли үзенчәлекне ачыклау;
-ру телендәге текстларны татарчага тәрҗемә итү.
Төп белем баскычларындаукучылар үзләштерегә тиешле мәгълүмат:
-өстәмә белем чыганакларыннан язычыларның тормышы һәм иҗаты турында;
-Татар әбиятының һәм сәнгатенең күренекле вәкилләре,аларның иҗаты турында;
-әдәби әсәрне,язучы иҗатын мөмкин кадәр мөстәкыйль анализлау,чор белән бәйләү өчен кирәкле булган тарихи,сәяси һ.б. мәгълүмат.
**10нчы сыйныф**
Төп гомуми һәм урта белем мәктәбе өчен үрнәк программа. “Рус телендә төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (I-XI сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа”,

төзүче-авторлары: Ф.Х. Җәүһәрова., Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.
Гамәлдәге авторлык программасы. «Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче с-флар", төзүче-авторы: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011, Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.
Эш программасы структурасы.
Татар әдәбиятыннан эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.
Татар әдәбиятын укытуның максатлары:

матур әдәбият текстларын форма һәм эчтәлек берлегендә аңлап кабул итү, төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне белү; әдәби-тарихи процесс турында гомуми караш булдыру;

тиз үзгәрүчән заман шартларында файдалы җитештерүчән хезмәткә яраклы, үз-үзен танып белергә һәм һәрдаим камилләштерергә әзер, рухи дөньясы бай булган шәхес тәрбияләү; гуманлылык карашлары,милли үзаң, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, әдәбиятка һәм халыкның мәдәни кыйммәтләренә ярату һәм хөрмәт булдыру;

укучыларда әдәбиятның үзенчәлекләре турында карашларны, образлы һәм аналитик фикерләү культурасын, автор позициясен аңлау, әдәби процессның тарихи һәм эстетик нигезләренә төшенү , эстетик һәм иҗади сәләтне, кызыксынуны үстерү;
Предметның укыту планында тоткан урыны: мәктәпнең 2015-2016 нчы уку елына уку-укыту планы нигезендә "Татар әдәбиятын"н атнага (35 атна) 2 шәр сәгать исәбеннән, елга 70 сәгать укыту каралган. Рус мәктәбендә укучы татар балаларына әдәбияттан тәкъдим ителә торган әсәрләр минимумы шул 70 дәрестән торган курска өстәлгән.

**11нче сыйныф.**

Төп гомуми һәм урта белем мәктәбе өчен үрнәк программа. "Рус телендә төп һәм урта белем бирү мәктәпләренең татар сыйныфлары (I-XI сыйныфлар) өчен татар әдәбиятыннан үрнәк программа", төзүче-авторлары: Ф.Х. Җәүһәрова., Казан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2013.
Гамәлдәге авторлык программасы. «Рус телендә урта (тулы) гомуми белем мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан үрнәк программалар: 1-11нче с-флар", төзүче-авторы: Ф. Ф. Харисов, Ч.М. Харисова, В.А.Гарипова. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән, Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2011, Татарстан Республикасы Менделеевск шәһәре «1 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесенең 2015-2016 нче уку елына укыту планына нигезләнеп төзелде.
Рус мәктәбенең 11 нче сыйныфы татар төркемнәрендә әдәбият укытуның максатлары:
1. Әдәби әсәрләргә таянып, иң яхшы сүз сәнгате үрнәкләрендә урын алган вакыйга-күренешләр аша татар халкы тормышы белән танышу, аның яшәешенә, төп проблемаларына, рухи дөньясына кагылышлы материалларны өйрәнү.
2. Мөстәкыйль рәвештә әдәби әсәрне анализларга, аны бәяләргә өйрәтү.
Төп бурычлар:
1. Укучыларның татар әдәби теле нормалары үзләштерүләренә, текстны аңлап, төрле темаларга иркен сөйләшүләренә ирешү.
2. Күренекле язучыларның иҗатын, аларның әсәрләрен үзләштерүләренә ирешү.
3. Укучыларга татар халкының килеп чыгышы, тарихи язмышы турында мәгълүматлар бирү.
4. Халык тарихын һәм мирасын өйрәнү аша яшүсмерләрдә Ватанга, халыкка,туган телгә мәхәббәт, кешегә ихтирам, мәрхәмәтлелек тәрбияләү, шулай ук эстетик, этик һәм хезмәт тәрбиясе бирү.
Сәгать саны: атнага – 2 сәгать (елына – 69 сәгать)
Арадаш аттестация эше: тест
Укыту дәрәҗәсе: база
Эш программасы үтәлү вакыты: 2015-2016 нчы уку елы
Мәктәпнең эш режимы: бер сменада 6 көнлек уку атнасы